**“Өч кыз” татар халык әкияте**

(татар төркемендә әдәби уку дәресе, 1 сыйныф)

**Хафизова Лидия Хәмзә кызы**

Казан шәһәре Совет районы 156нчы номерлы гомуми белем бирү мәктәбенең туган тел укытучысы

**Максат:**

- *дидактик:* бәйләнешле сөйләм, уку күнекмәләре формалаштыру; әкият төрләрен аера белергә өйрәтү;
- *үстерешле:* логик һәм иҗади фикер эшчәнлеге өчен җирлек тудыру;
- *тәрбияви:* укучыларда әкият геройларына карата мөнәсәбәт формалаштыру.

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Предмет буенча:*

- әкиятне аңлап уку, геройларның уңай һәм тискәре сыйфатларын билгеләү; сорауларга җавап бирү;
- әкият укуга карата кызыксыну уяту;
- сәнгатьле һәм йөгрек укуга ирешү.

**Метапредмет (УУГ):**

*Регулятив (РУУГ):*

- максатны гамәлгә ашыру чараларын сайлап алу һәм аларны куллану;
- план төзү һәм гамәлләр тәртибен ачыклау;
- үтәлгән эшнең уңышлыгына бәя бирү.

*Коммуникатив (КУУГ):*

- әңгәмәдә катнашу;
- диалог төзү;
- парларда һәм төркемнәрдә эшләгәндә бер-береңнең сөйләмен контрольгә алу, төзәтү һәм бәяләү.

*Танып белү (ТБУУГ):*

- әкиятне үзләштерүдә төрле алымнар куллана белү,иҗади якын килү;

- әкият геройларын чагыштыру һәм сыйфатларына карап төркемләү.

*Шәхескә кагылышлы (ШУУГ):*

- уңай һәм тискәре сыйфатларны аерарга өйрәнү;
- үзеңдә уңай сыйфатлар тәрбияләргә этәргеч ясау, ә тискәре сыйфатларга каршылыклы фикер уяту.

**Дәрес тибы:** яңа белемнәр үзләштерү.

**Предметара бәйләнеш:** рәсем һәм сынлы сәнгать, әйләнә-тирә дөнья, музыка.

**Эшчәнлекне оештыру формалары:** фронталь, парлап, индивидуаль, төркемдә.

**Материал һәм җиһазлау:** дәреслек (1 нче сыйныф өчен дәреслек: Әлифба: рус телендә башл. Гомуми белем бирү мәкт. 1 нче с-фы өчен д-лек (татар телендә сөйләшүче балалар өчен) / Ф.Ш. Гарифуллина, И.Х. Миассарова; [рәссамы Л.С.Золондинова]. – Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2012. – 111б.:рәс.б-н.), “Өч кыз” әкиятенә нигезләнгән мультфильм, әниләр турында мәкальләр, гыйбәрәләр, экран, ноутбок.

Дәреснең технологик картасы

| **Дәрес этаплары** | **Укытучы эшчәнлеге** | **Укучы эшчәнлеге** | **Универсаль уку гамәлләре** |
|---|---|---|---|
| **I.Оештыру мотивлаштыру** (Исәнләшү. Уңай психологик | «Исәнмесез», диеп башлыйм әле,<br>Һәр дәрес бит шулай башлана.<br>“Исәнмесез”, диеп сүз башласак,<br>Бәхет арта, күңел шатлана. | Укучылар учларын алга куялар һәм барлык теләгән теләкләрен | ШУУГ: укучылар арасында дустанә мөнәсәбәт, укытучыга |

| | | | |
|---|---|---|---|
| халәт тудыру) | Исәнменсез, укучыларым!<br>Хәерле көннәр сезгә! Көнне башлаганда һәрбер кеше изгелекләр теләргә, бер-берсенә яхшы сүзләр әйтеп елмаерга тиеш. Иртәне елмаеп башласаң, көнең дә матур үтәр. Укучыларым, әйдәгез, бер-беребезгә карап елмаеп, исәнләшеп алыйк әле. | шунда әйтеп салалар һәм өскә ыргыталар. Бер-берләренә борылып елмаялар һәм исәнләшәләр. | хөрмәт;<br><br>КУУГ: сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;<br>РУУГ:эш урыннарын әзерләү |
| **II.Актуальләштерү** | -Борын-борын заманда яшәгән ди, булган ди, бик зирәк әби белән бабай, бик җитез кыз белән малай. Алар дөнья гизгәннәр, төрле маҗараларга очраганнар.<br>-Борын-борын заманда яшәгән ди, булган ди кәҗә белән сарык.<br>- Укучылар, без шушы җөмләләрне кайсы китапларда бик еш очратабыз әле? Беләсезме? | - Әйе. Беләбез. Бу җөмләләр белән без яратып укый торган әкиятләр башлана бит.<br>Без әкиятләр укырга яратабыз. Кечкенә вакытта ук безгә | ШУУГ: әкиятләр укырга кызыксындыру;<br>КУУГ: әңгәмәдә катнаша алу, үз фикереңне курыкмыйча җиткерү<br><br><br>ТБУУГ: |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | аларны әниләребез, әбиләребез сөйлиләр иде.<br>Хәзер үзебез аларны укыйбыз. | әкиятләрне искә төшерү |
| | -Укучылар, нинди әкиятләр беләсез? | -“Шүрәле”, “Су анасы”, “Шалкан”, “Кәҗә белән сарык”, “Куян кызы”, “Торна белән төлке”<br>һ.б.ш. | |
| **III. Уку мәсьәләсен кую** | -Шушы күтәренке күңел белән әкиятләр турында сөйләшүебезне дәвам итеп, бер ребус чишеп карыйк әле. Шуны дөрес итеп чишсәк, бүген өйрәнәчәк әкиятебезнең исеме килеп чыгарга тиеш.<br>Ребус: | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | <br>-Бик дөрес, укучылар. Без бүген сезнең белән татар халкының “Өч кыз” әкияте белән танышырбыз. | -“Өч кыз” әкияте. | ТБУУГ: өйрәнеләчәк материалны ачыклау;<br>РУУГ: эшчәнлекне оештыра белү |
| **IV. Уку мәсьәләсен чишү** | -Бу әкият нәрсә турында булыр икән?<br>-Дөрес уйлыйсыз. Әсәрне укый башлаганчы без сезнең белән “Өч кыз” әкияте нигезендә төшерелгән мультфильм карап китик әле. (Экран ярдәмендә мультфильм күрсәтелә.) | -Өч кыз турында.<br>-Әни турында. | ТБУУГ: мультфильм ярдәмендә бирелгән информацияне аңлый белү, нәтиҗә чыгару |
| | -Кайсыгыз әкиятнең авторын әйтә ала? | - Татар халкы иҗат иткән. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | -Халык әкияте белән автор әкияте арасында нинди аерма бар? | -Автор әкиятләренең кем язганы билгеле, ә халык әкиятләренең авторы билгеле түгел. | |
| | -Сез тагы нинди халык әкиятләрен беләсез? | -Рус, украин,әрмән һ.б.ш. | ШУУГ: милләтләр арасындагы бәйләнеш |
| | -Әкияттә төп геройлар кемнәр? | -Әни, беренче кыз, икенче кыз, өченче кыз, тиен. | |
| | -Барлыгы ничә герой? | -5 герой. | |
| | -Геройларга характеристика бирик әле? | Укучылар уңай һәм тискәре геройларны саныйлар. | ШУУГ: |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | -Ә тиенне тискәре геройга кертеп карый алабызмы?<br><br>-Тиенне без уңай герой итеп карыйбыз. Чөнки тиен кызларны акылга утырту өчен шулай эшли.<br><br>-Ә өченче кыз турында ни әйтә аласыз?<br><br>-Әйе, укучылар. Бик дөрес. Әни кеше өчен иң кыйммәтле, иң кадерле зат. Әниләребездә кояш җылылыгы да, йолдызлар нуры да бар. Әниләрне һәрвакыт яратырга кирәк. Авырган вакытларында яннарында булырга, ярдәм кулы сузарга тиешбез. Әниләребезгә карата бик күп мәкальләр дә бар бит.<br>Ана – шәфкать диңгезе.<br>Өйнең яме ана белән.<br>Ана балага авызыннан өзеп каптырыр. | -Әйе. Ул беренче кызны бакага, икенче кызны үрмәкүчкә әверелдерә.<br>-Юк. Тиен уңай герой. Ул аларны әниләренә ярдәм итәргә бармаганга күрә бакага, үрмәкүчкә әверелдерә.<br>-Әнисен ярата,хөрмәт итә.<br>-Уңган, ярдәмчел.<br>-Өченче кыз урынында, чөнки ул камырлы кулларын да юып тормыйча, | Яхшы һәм тискәре сыйфатларны аера белү;<br><br>КУУГ: үзара ярдәмләшеп эшли белү;<br><br>РУУГ: үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | -Сез кайсы кыз урынында булыр идегез? | әнисе янына йөгерә. | |
| **V.Ял минуты** | Ә хәзер бераз ял итеп алыйк. (Әкерне генә музыка уйный). Укытучы шигырь сөйли. Укучылар шигырьгә бәйле күнегүләр ясыйлар.<br>Ак куянкай утырган,<br>Колакларын селкетә.<br>Менә шулай, менә шулай,<br>Колакларын селкетә.<br>Куян туңа башлагач<br>Аякларын җылыта.<br>Куян һаман да туңа,<br>Сикергәләп тә куя.<br>Менә шулай, менә шулай,<br>Сикергәләп тә куя.<br>Кемдер аны куркытты,<br>Ул урманга элдертте. | Укучылар куян ролендә кереп төрле күнегүләр ясыйлар. | |
| **VI. Яңа теманы ныгыту** | -Ә хәзер бераз хыялланып алыйк әле. Әгәр дә сез автор булсагыз, шушы әкиятне ничек дәвам итәр идегез? | - Укучылар төрлечә әкиятнең дәвамын сөйләп карыйлар. | КУУГ: йөгерек, сәнгатьле уку күнекмәсен ныгыту |
| | Китапларда “Өч кыз” әкиятен ачу. Дәреслек белән эш. | Укучылар белән рольләргә | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | бүлеп укырга тырышу. | |
| **VII. Йомгаклау. Рефлексив кабатлау.** | -Шулай итеп, укучылар, без бүгенге дәресебездә нинди әкият белән таныштык?<br><br>-Әкиятнең авторы бармы?<br><br>-Бу әкиятләр безне нинди булырга өйрәтә?<br>-Ярый, укучылар. Булдырдыгыз! Дәрестә бик актив булдыгыз. Бүген үзләштергән белемнәр сезгә тормышта ярдәм итәр дип уйлыйм. Дәрес тәмам. Игътибарыгыз өчен рәхмәт. | Сорауларга җавап бирәләр, әңгәмәдә катнашалар. Укчылар үз-үзләренә бәя бирәләр. | КУУГ: фикерләрне төгәл һәм ачык итеп әйтә белү |